**РАСПОРЯЖЕНИЕ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**БОЕРЫГЫ**

23.06.2023 № 212

**Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының интерактив мәгълүмат-аналитика системасын төзү мәсьәләләре буенча эш төркемен оештыру турында» боерыгына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының интерактив мәгълүмат-аналитика системасын төзү мәсьәләләре буенча эш төркемен оештыру турында» боерыгына (Татарстан Республикасы Президентының 2019 елның 6 маендагы 171 номерлы, 2019 елның 21 декабрендәге 430 номерлы һәм 2020 елның 2 июлендәге 210 номерлы боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

атамасында «Татарстан Республикасының интерактив мәгълүмат-аналитика системасын төзү» сүзләрен «Татарстан Республикасы бердәм ведомствоара электрон документлар әйләнеше системасының «Контроль» модуленең эшләве» сүзләренә алмаштырырга;

преамбулада «Татарстан Республикасының интерактив мәгълүмат-аналитика системасын төзү» сүзләрен «Татарстан Республикасы бердәм ведомствоара электрон документлар әйләнеше системасының «Контроль» модуленең эшләве» сүзләренә алмаштырырга;

1 пунктта «Татарстан Республикасының интерактив мәгълүмат-аналитика системасын төзү» сүзләрен «Татарстан Республикасы бердәм ведомствоара электрон документлар әйләнеше системасының «Контроль» модуленең эшләве» сүзләренә алмаштырырга;

2 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

Татарстан Республикасының интерактив мәгълүмат-аналитика системасын төзү мәсьәләләре буенча эш төркеме составын кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

**Татарстан Республикасы Рәисе** — **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РӘИСЕ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ • АДМИНИСТРАЦИЯ РАИСА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Татарстан Республикасы
Рәисенең
2023 елның «23» июнендәге
212 номерлы боерыгына
кушымта

**Татарстан Республикасы бердәм ведомствоара электрон документлар әйләнеше системасы «Контроль» модуленең эшләве мәсьәләләре буенча эш төркеме составы**

| | |
|---|---|
| Сәфәров<br>Әсгать Әхмәт улы | Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе, эш төркеме җитәкчесе |
| Савельев<br>Игорь Леонидович | Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе урынбасары – Татарстан Республикасы Рәисенең Эксперт департаменты җитәкчесе, эш төркеме җитәкчесе урынбасары |
| Шаһиәхмәтов<br>Мидхәт Рәфкать улы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы икътисад министры, эш төркеме җитәкчесе урынбасары |
| Вәгыйзов<br>Айдар Рамил улы | Татарстан Республикасы Рәисенең Эксперт департаменты җитәкчесе урынбасары – Департаментның Икътисадый анализ идарәсе башлыгы, эш төркеме секретаре |
| Гайнетдинов<br>Ренат Вагыйзь улы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Икътисад, финанс һәм дәүләт мөлкәте белән эш итү идарәсе башлыгы |
| Гарипов<br>Илнур Мәхмүт улы | Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесенең беренче урынбасары – Татарстан Республикасы Рәисенең Территорияләр белән эшләү идарәсе башлыгы |

| | |
|---|---|
| Гатауллина<br>Наталья Вячеславовна | Дәүләт статистикасы федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча территориаль органы җитәкчесе (килешү буенча) |
| Кудрявцева<br>Алевтина Николаевна | «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасының Икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе директоры |
| Миңнеханов<br>Рифкать Нургали улы | «Юл хәрәкәте иминлеге» дәүләт бюджет учреждениесе директоры |
| Нәфыйгин<br>Альберт Илдар улы | Татарстан Республикасы Рәисе ярдәмчесе |
| Огородников<br>Алексей Игоревич | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Мәгълүмат технологияләре, элемтә һәм мәгълүматны саклау идарәсе башлыгы |
| Хәйруллин<br>Айрат Ринат улы | Татарстан Республикасы дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министры |
| Якубов<br>Тимур Эдуард улы | «Мәгълүмати проектларга идарә» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директоры (килешү буенча) |

___________